# КАРАР

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче
Черемушка авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре хакында

2019 елның 25 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькиноо авылы җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авылы җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " карары», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының « Емелькино авылы җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 24 статьясы нигезендә Аксубай муниципаль районының Емелькино авылы җирлеге Черемушка бистәсендә 2019 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Аксубай муниципаль районы Емелькино авылы җирлегенең Черемушка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Черемушка авылы юлларын агымдагы төзекләндерү (вак таш, ЩПС сатып алу, вак таш салу, грейдлау, торбалар алу);

**Күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Черемушка авылы чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 103 кеше, җыенда катнашучылар саны 61 кеше кергән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде 61 катнашучы гражданнар җыенында;
- «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде 0 катнашучы гражданнар җыенында.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Емелькино авыл җирлеге составына керүче Черемушка авылында гражданнар җыенын – узган дип, ә халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

«Сез килешәсезме:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Черемушка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш) 300 сум күләмендә үзара салым кертү);

2. түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

***Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:***

- Черемушка авылы юлларын агымдагы төзекләндерү (вак таш, ЩПС сатып алу, вак таш салу, грейдлау, торбалар алу);

**Күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Черемушка авылы чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу?»

3.Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Емелькино авылы җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы Н.И.Михайлова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" СОВЕТ ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ